# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**Административ хокук бозулар турында**
**Татарстан Республикасы кодексына**
**үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2012 елның 29 ноябрендә
кабул ителде

**1 статья**

Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, 12 (I өлеш); 2007, № 11; 2009, № 2, № 7 – 8 (I өлеш), № 9 – 10, № 12 (I өлеш); 2010, № 1 – 2, № 3, № 6 (I өлеш), № 7 (I өлеш), № 7 (II өлеш), № 10 (II өлеш); 2011, № 6 (I өлеш), № 8 (I өлеш), № 10 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2012, № 1; Ватаным Татарстан, 2012, 20 июнь, 24 июль) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 3.14 статья өстәргә:
"3.14 статья. **Мәдәни-тамаша һәм спорт чараларында булганда иҗтимагый тәртипне бозу**

Мәдәни-тамаша, спорт чаралары уздыру вакытында тамашачылар спорт мәйданчыгына, уен кырына, йөгерү юлына, манежга, сәхнәгә (шул исәптән боз сәхнәгә) үз белдеге белән чыккан өчен –

гражданнарга биш йөздән бер мең сумга кадәр күләмдә административ штраф салына;

ел дәвамында шул ук гамәлләрне кабат кылган өчен –

гражданнарга бер меңнән өч мең сумга кадәр күләмдә административ штраф салына.

Трибунага, спорт мәйданчыгына, уен кырына, йөгерү юлына, манежга, сәхнәгә (шул исәптән боз сәхнәгә), су объекты акваториясенә мәдәни-тамаша һәм спорт чаралары үткәрүгә комачаулый торган ят әйберләр ташлаган өчен –

гражданнарга бер меңнән ике мең сумга кадәр күләмдә административ штраф салына;

ел дәвамында шул ук гамәлләрне кабат кылган өчен – гражданнарга өч меңнән биш мең сумга кадәр күләмдә административ штраф салына.";

2) 7.1 статьяда:

а) "3.12," саннарын төшереп калдырырга;

б)"3.13," саннарыннан соң "3.14," саннарын өстәргә;

3) 8.1 статьяның икенче өлешендә "3.11 – 3.13" саннарын "3.11, 3.13, 3.14" саннарына алмаштырырга.

**2 статья.** Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2012 елның 17 декабре
№ 85-ТРЗ